# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

03 февраль 2025 ел № 1 Урыссу ш.т.б.

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактаулы гражданины турында"гы нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Ветераннар турында»гы 12.01.1995 елның № 5-ФЗ санлы Федераль законы, Россия Федерациясе Президентының «1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү турында»гы 31.07.2023 елның № 568 санлы Указы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның № 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Президенты В. В. Путин, Татарстан Республикасы Рәисе Р. Н. Миңнеханов йөкләмәләрен үтәү максатларында һәм 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын һәм Татарстан Республикасында Ватанны саклаучы елын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны үткәрү кысаларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 15.09.2021 елның № 65 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Мактаулы гражданины» турындагы нигезләмәгә (алга таба - нигезләмә) түбәндәге өстәмә кертергә:

1.1. Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 5 нче статья өстәргә:

«5 Статья.

1. Мактаулы гражданин исеме Ютазы районы территориясендә әлеге Нигезләмәнең 1 статьясындагы 3, 5, 6 өлешләрендә, 3 статьясындагы 1, 2, 3, 4 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәмичә яшәүче 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында (алга таба - Бөек Ватан сугышында катнашучы) катнашучыларга бирелә.

Бөек Ватан сугышында катнашучыга мактаулы гражданин исеме бирү турындагы карар район башлыгының Бөек Ватан сугышында катнашучыга мактаулы гражданин исеме бирү турындагы тәкъдиме нигезендә район Советы тарафыннан кабул ителә.

Бөек Ватан сугышында катнашучыга мактаулы гражданин исеме бирү турындагы карар район Советына район башлыгының тиешле тәкъдиме кергән көннән алып өч эш көне эчендә кабул ителә.».

2. Әлеге карарны адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин